РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул.Ленина, д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
23.12.2025

КАРАР
№ 41

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннарын булдыру турында

РФ Хөкүмәтенең “Яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урыннан-урынга күчерү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган өлешендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында” 28.12.2020 елгы №2314 карарының 5 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннары булдырырга, шул исәптән мондый туплау урыннарын оештыру күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен урыннар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракларда, түбәндәге адрес буенча:

- Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Иске Икшермә авылы, Пушкин урамы, 3А, Иске Икшермә авыл җирлегенең административ бинасы, бүлмә 5.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны җирлекнең рәсми сайтында, җирлекнең түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә: ТР, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Пушкин ур., 2; ТР, Саба районы, Татар Икшермәсе авылы, Гагарин ур., 16; ТР, Саба районы, Өч Нарат авылы, Татарстан ур., 41А.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл башкарма комитетының «Терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм

урнаштыру урыннарын раслау турында» 10.02.2014 елгы № 5 карарын үз кечен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, җирлекнең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында: ТР, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Пушкин ур., 2; ТР, Саба районы, Татар Икшермәсе авылы, Гагарин ур., 16; ТР, Саба районы, Өч Нарат авылы, Татарстан ур., 41А.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы: А.И.Биккинин